**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6980**
**23.11.2018**

Яр Чаллы шәһәрен
Яңа елга иң яхшы бизәү
буенча конкурс үткәрү турында

Яр Чаллы шәһәрен Яңа елга бизәүне оештыру максатында

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсенә 2018 елның 21 декабреннән 2019 елның 13 гыйнварына кадәр Яр Чаллы шәһәрен Яңа елга иң яхшы бизәү буенча конкурс үткәрергә.

2. Расларга:

1) Яр Чаллы шәһәрен Яңа елга иң яхшы бизәү буенча конкурс үткәрү турында нигезнамәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) Яр Чаллы шәһәрен Яңа елга иң яхшы бизәү буенча конкурска йомгак ясау комиссиясе составын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2018 елның 23 ноябрендәге
6980 нче карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәрен
Яңа елга иң яхшы бизәү буенча конкурс үткәрү турында
нигезнамә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге нигезнамә Яр Чаллы шәһәрен Яңа елга иң яхшы бизәү буенча конкурс (алга таба – конкурс) оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели.

2. Конкурсның максатлары һәм бурычлары:

1) Яңа ел бәйрәмнәрендә Яр Чаллы шәһәре халкы өчен бәйрәм атмосферасы тудыру;

2) биналарның, урамнарның, мәйданнарның, чыршыларның сәнгатьчә, утлар белән бизәлешен яхшырту.

2 бүлек. Конкурсны оештыру һәм үткәрү тәртибе

3. Конкурста түбәндәге номинацияләр буенча физик, юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр катнаша ала:

1) «Район Яңа ел чыршысын иң яхшы бизәү»;

2) «Микрорайон территориясен Яңа елга иң яхшы бизәү». Номинациядә катнашучылар – территориаль иҗтимагый үзидарәләр (алга таба – ТИҮ);

3) «Оешма территориясен Яңа елга иң яхшы бизәү». Номинациядә катнашучылар 3 категориягә бүленә:

- бюджет оешмалары;
- коммерцияле оешмалар (сәнәгать предприятиеләреннән тыш);
- сәнәгать предприятиеләре.

4. Конкурста катнашу өчен заявкаларны, әлеге нигезнамәгә кушымтада каралган форма буенча, 2018 елның 20 декабренә кадәр электрон почта аша шәһәрнең тиешле районында кабул итәләр:

1) Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте: avtoispolcom@mail.ru, белешмәләр өчен телефон: 54-76-76, 32-98-36;

2) Башкарма комитетның Үзәк районы хакимияте: ykx.a@yandex.ru, белешмәләр өчен телефон: 47-55-49, 47-55-39;

3) Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте: ikkr@mail.ru, белешмәләр өчен телефон: 71-42-24, 70-17-59.

Заявкага конкурска куела торган объектның икедән ким, ләкин алтыдан артык булмаган санда электрон рәвештәге фотосы теркәлә.

5. Конкурс 2 этапта үткәрелә.

Конкурсның беренче этабы шәһәрнең һәр районында 2018 елның 21 декабреннән 2018 елның 27 декабренә кадәр үткәрелә. Беренче этапта җиңүчеләр Башкарма комитетның район хакимиятләре оештырган комиссияләр тарафыннан билгеләнә.

Конкурсның икенче этабында катнашу өчен, конкурсның беренче этабы нәтиҗәләре нигезендә һәр район һәм һәр номинация буенча икешәр җиңүче күрсәтелә. Конкурсның беренче этабы нәтиҗәләре 2018 елның 28 декабренә кадәр шәһәр комиссиясенә җибәрелә торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Конкурсның икенче этабы 2018 елның 28 декабреннән 2019 елның 12 гыйнварына кадәр үткәрелә. Конкурска йомгак Яр Чаллы шәһәрен Яңа елга иң яхшы бизәү буенча конкурска йомгак ясау комиссиясе (алга таба – шәһәр комиссиясе) тарафыннан ясала, аның составы Башкарма комитет карары белән раслана.

## 3 бүлек. Конкурсның бәяләү критерийлары

6. «Район Яңа ел чыршысын иң яхшы бизәү» номинациясе буенча конкурсның төп бәяләү критерийлары булып түбәндәгеләр тора:

1) сәнгатьчә бизәлеш дәрәҗәсе;

2) Яңа ел чыршысын иллюминация утлары белән бизәү;

3) янәшә территорияне бизәү (боз шәһәрчекләре, кардан ясалган фигуралар, таулар);

4) бизәү үзенчәлеге, инновацион якын килү.

7. «Микрорайон территориясен Яңа елга иң яхшы бизәү» категориясенең төп бәяләү критерийлары булып түбәндәгеләр тора:

1) микрорайон территориясендәге оешма биналарын һәм торак йортларны Яңа елга сәнгатьчә бизәү дәрәҗәсе;

2) микрорайон территориясендәге биналарда һәм корылмаларда котлау язулары булу;

3) микрорайон территориясендәге биналарны иллюминация утлары белән бизәү (микрорайон территориясендәге биналарның гомуми санына карата иллюминация утлары белән бизәлгән биналар саны);

4) бизәү үзенчәлеге;

5) микрорайон территориясен Яңа елга бизәүдә шәһәр халкының катнашуы.

8. «Оешма территориясен Яңа елга иң яхшы бизәү» номинациясе буенча конкурсның төп бәяләү критерийлары булып түбәндәгеләр тора:

1) бинаның һәм бина янәшәсендәге территориянең сәнгатьчә бизәлеш дәрәҗәсе;

2) котлау язулары булу;

3) бинаны һәм территорияне иллюминация утлары белән бизәү;

4) бинаны һәм территорияне бизәү үзенчәлеге, инновацион якын килү.

## 4 бүлек. Комиссия эшен оештыру

9. Конкурста катнашучыларны бәяләү, әлеге нигезнамәнең 3 бүлегендә билгеләнгән критерийларга туры китереп, биш баллы система буенча башкарыла.

10. Шәһәр комиссиясе карары утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм утырышта катнашучы комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

11. Иң күп тавыш җыйган катнашучы конкурсның җиңүчесе булып исәпләнә.

12. Конкурста җиңүчеләр дипломнар белән бүләкләнә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Н.И. Галиева

Яр Чаллы шәһәрен Яңа елга иң яхшы бизәү буенча конкурс үткәрү турында нигезнамәгә кушымта

Форма

Яр Чаллы шәһәрен Яңа елга иң яхшы бизәү буенча конкурста катнашуга заявка

Яр Чаллы шәһәрен Яңа елга
иң яхшы бизәү буенча конкурска
йомгак ясау комиссиясе рәисе,
Башкарма комитет Җитәкчесе
Р.Ә. Абдуллинга

Мин, ________________________________________________________________

Предприятие җитәкчесенең Ф.И.А.и. ______________________ (предприятиенең, оешманың тулы исеме),

________________________________________________________________

(Вазыйфасы, эш урыны)

________________________________________________________ номинациясендә

______________________________________________________________ категориядә

Яр Чаллы шәһәрен Яңа елга иң яхшы бизәү буенча конкурста катнашуга заявка кабул итүегезне сорыйм.

Предприятиенең почта һәм фактик адресы ______________________________________

________________________________________________________________

Элемтә телефоны ________________________________________________________

Кушымта: конкурска куела торган объектның фотосы, электрон рәвештә, 2-6 данә.

Дата — Гариза бирүченең имзасы

Башкарма комитетның
2018 елның 23 ноябрендәге
6980 нче карарына
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәрен
Яңа елга иң яхшы бизәү буенча конкурска йомгак ясау комиссиясе
составы

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. | Абдуллин Ринат Әзһәр улы | - | комиссия рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе |
| 2. | Зуев Илья Сергеевич | | комиссия рәисе урынбасары, Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары |
| комиссия әгъзалары: | | | |
| 3. | Галимов Искәндәр Нургаләм улы | - | Башкарма комитетның Үзәк районы хакимияте Башлыгы |
| 4. | Идрисов Алмас Әхтәм улы | - | Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе башлыгы урынбасары, шәһәрнең баш архитекторы вазыйфаларын башкаручы |
| 5. | Кыямов Рафаил Әгъләметдин улы | - | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы |
| 6. | Кислов Александр Иванович | - | Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте Башлыгы |
| 7. | Кропотова Наталия Анатольевна | - | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| 8. | Усманова Раушан Мәсгут кызы | - | Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте Башлыгы |
| 9. | Хәлимов Рамил Мәрван улы | - | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары. |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Н.И. Галиева